**Татарстан Республикасы Азнакай район Советы**
**дүртенче чакырылыш**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 244-27 «25» октябрь 2023 ел

Татарстан Республикасы Азнакай районы Советының 2021 елның 29 сентябрендәге 81-10 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы нигезләмә хакында» карары белән расланган, автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (14.12.2021 №103-12, 25.02.2022 №118-15, 08.06.2023 №229-25) карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай районы Советының 2021 елның 29 сентябрендәге 81-10 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында нигезләмә хакында» карары белән расланган, автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы Нигезләмәгә (14.12.2021 №103-12, 25.02.2022 №118-15, 08.06.2023 №229-25 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә 2 нче кушымтаны яңа редакциядә әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль район Советы
карарына 1 нче кушымта
«25» октябрь 2023 ел № 244-27

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге

1. Автомобиль транспортында, шәһәр, җир өсте, электр транспортында, йөртүчеләр тарафыннан кылынган, даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу кагыйдәләрен бозу фактларын бер календарь ел дәвамында, алдагы календарь ел белән чагыштырганда, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр Министрлыгы тарафыннан бирелгән мәгълүматлар нигезендә биш процентка һәм аннан күбрәк бозу фактларына арттыру.

2. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр Министрлыгы тарафыннан бирелгән мәгълүматларга нигезләнеп, бер календарь ел дәвамында юл инфраструктурасы объектында юл-транспорт һәлакәтләре санын ике тапкырга һәм аннан да күбрәк тапкырга арттыру.

3. Контрольдә тотыла торган зат карамагындагы яисә аннан файдаланудагы юл участогында юл-транспорт һәлакәтләренең узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, календарь айга биш процентка артуы.